СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 19 » февраль 2016 ел** **№ 34**

**Арча район Советының**
**31.01.2011 № 31.3 (27.12.2013 №243.1 06.05.2014 № 268 үзгәрешләре белән) карары белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты структурасын камилләштерү, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан Арча район Советы карар бирде:

Арча район Советының 2011 елның 31 гыйнварындагы 31.31.3 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты турында Нигезләмәгә (27.12.2013 №243.1, 06.05.2014 № 268) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Аппарат структурасы» дигән 3.1 статьядагы 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль район башкарма комитеты аппаратына түбәндәгеләр керә:

1. Башкарма комитетның эшләр идарәчесе.

2. Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе.

3. Оештыру-гомуми бүлек:

- архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару секторы;

мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм мәгълүматны яклау секторы.

4. Инфраструктура үсеше бүлеге:

- шәһәр төзелеше һәм архитектура секторы;

- ТКХ, энергетика һәм элемтә секторы.

5. Икътисад һәм финанс бүлеге:

6. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге.

7. Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге.

8. ГХАТ бүлеге.

9. Опека һәм попечительлек секторы

Башкарма комитет аппараты хезмәткәрләренең структурасы һәм саны башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе                                        И.Г. Нуриев